| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**31.03.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 731** |

Зеленодольск муниципаль районының 2013-2016 еллардагы авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү программасы буенча торак йортларны коммуникацияләрдән өзү турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күп фатирлы йортлары исемлеген раслау турында» 2014 елның 31 июлендәге 1553 номерлы карарына, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 декабрендәге 3622 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында 2013-2017 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2017елның 06 февралендәге 176 номерлы ярашлы рәвештә, йортлардан күчеп киткәннәрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Водоканалсервис» ААҖ филиалы - «Зеленодольск-Водоканал» предприятиесенә , – «Татэнергосбыт» ААҖ-Идел буе бүлекчәсенең Зеленодольск ОКО , «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ҖЧҖ түбәндәге адрес буенча торак йортны авария хәлендәге тиешле төрдәге коммуникацияләрдән сүндерергә тәкъдим итәргә:

-РТ, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Почта ур., 38 нче йорт.

2. Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча торак урыннарның социаль найм килешүен өзәргә:

-РТ, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Почта ур., 38 нче йорт.

3. «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән урыннарны билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль милек реестрыннан чыгаруны тәэмин итәргә, күчерелгән торак йортларның җир

кишәрлекләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмага тапшырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин